Раслыйм»
Татарстан Республикасы
Чистай муниципаль районы
«Чистай шәһәре» муниципаль
берәмлегенең җирдән файдалану һәм
төзелеш кагыйдәләре буенча комиссия
рәисе

________________________И.Ф. Рәхимов

№ 11
2022 елның 26 октябре

«Чистай шәһәре» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү проекты буенча ачык тыңлаулар нәтиҗәләре һәм җир кишәрлегеннән шартлы рәвештә файдалануга рөхсәт бирү мәсьәләсе буенча

**БӘЯЛӘМӘ**

Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы «Чистай шәһәре» муниципаль берәмлеге башлыгының «Ачык тыңлауларны билгеләү турында» 2022 елның 6 октябрендәге 20 номерлы, «Җир кишәрлегеннән шартлы рәвештә файдалануга рөхсәт бирү мәсьәләсе буенча ачык тыңлауларны билгеләү турында» 2022 елның 6 октябрендәге 21 номерлы карарлары белән билгеләнгән ачык тыңлаулар 2022 елның 26 октябрендә 10 сәгатьтә 00 минутта Чистай муниципаль районы Башкарма комитетының конференц залында түбәндәге адрес буенча узды: Татарстан Республикасы, Чистай муниципаль районы, Чистай шәһәре, Бебель ур., 129 нчы йорт.

«Чистай шәһәре» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү һәм җир кишәрлегеннән шартлы рөхсәт ителгән файдалану төренә рөхсәт бирү мәсьәләсе буенча 2022 елның 26 октябрендәге 11 номерлы ачык тыңлаулар үткәрү беркетмәсе

**Ачык тыңлаулар предметы:**

1. «Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы «Чистай шәһәре» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында» Чистай муниципаль районы Чистай шәһәр Советының карары проекты буенча ачык тыңлаулар үткәрү турында Чистай муниципаль районы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасы мөрәҗәгатен карау:

- «Рекреацион билгеләнештәге зона» Р2 территориаль зонасы чикләрен үзгәртү һәм Чистай шәһәре чикләренә, шул исәптән кадастр номеры 16:54:020101:241 булган җир кишәрлеген, «I-II класслы куркынычлылык җитештерү һәм склад объектлары зонасы» П1 зонасына кертү өлешендә;
- «Рекреацион билгеләнештәге зона» Р2 территориаль зонасы чикләрен үзгәртү һәм Чистай шәһәре чикләренә, кадастр номеры 16:54:020101:242 булган җир кишәрлеген, «I-II класслы куркынычлылык җитештерү һәм склад объектлары зонасы»П1 зонасына кертү өлешендә.

2. Кадастр номеры 16:54:100304:418 булган, 1671 кв.м. мәйданлы, түбәндәге адрес буенча урнашкан җир кишәрлегеннән шартлы рәвештә файдалануга рөхсәт бирү мәсьәләсе буенча ачык тыңлаулар үткәрү турында «Чистай дәүләт тарихи-архитектура һәм әдәби музей-тыюлыгы» ТР ДБМУ мөрәҗәгатен карау:

Татарстан Республикасы, Чистай муниципаль районы, Чистай шәһәре, К.Маркс ур., 76 нчы йорт - «Мәдәни-ял объектлары» «Шәхси торак төзелеше зонасы» Ж1 зонасында.

**Карар иттеләр:**

1. Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының «Чистай шәһәре» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү һәм җир кишәрлегеннән шартлы рәвештә файдалануга рөхсәт бирү мәсьәләсе буенча ачык тыңлауларны узды дип санарга.

2. «Чистай дәүләт тарихи-архитектура һәм әдәби музей-тыюлыгы» ТР ДБМУнә, кадастр номеры 16:54:100304:418 булган, 1671 кв.м. мәйданлы, түбәндәге адрес буенча урнашкан җир кишәрлегеннән шартлы рәвештә файдалануга рөхсәт бирергә: Татарстан Республикасы, Чистай муниципаль районы, Чистай шәһәре, К.Маркс ур., 76 нчы йорт - «Мәдәни-ял объектлары» «Шәхси торак төзелеше зонасы» Ж1 зонасында.

3. Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының «Чистай шәһәре» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәреш кертү турындагы проектны хупларга һәм раслау өчен «Чистай шәһәре» муниципаль берәмлеге Советына җибәрергә.

4. Әлеге бәяләмәне Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының рәсми сайтында (chistopol.tatarstan.ru) урнаштырырга.

Комиссия секретаре: ____________________Хөснетдинов А.Н.